Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Янсуар авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Янсуар авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

11 ноябрь, 2019 ел № 2

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Янсуар`авыл жирлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар жыеннарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законының 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында жирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Янсуар авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Янсуар авыл җирлегендә түбәндәге торак пунктларда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыеннарын билгеләргә:

1.1. Талкыш авылында. 2019 елның 24 ноябрендә 11 сәгать 00 минутта Кооператив урамы буенча 10 номерлы йорт янында гражданнар жыенын үткәрергә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез, 2020 елда Янсуар авыл жирлеге Талкыш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 төркем инвалидларны, биш һәм аннан да күбрәк балалы гаиләләрне бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм жирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- гомуми файдаланудагы урыннарны төзекләндерү

«РИЗА» «КАРШЫ».

1.1. Янсуар авылында. 2019 елның 30 ноябрендә 11 сәгать 00 минутта Үзәк урамының 1йортында урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында халык җыенын уздырырга.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез, 2020 елда Янсуар авыл жирлеге Янсуар торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 төркем инвалидларны, 5 һәм аннан да күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләрне бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм жирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау

«РИЗА» «КАРШЫ».

1.2. Нырсуар авылында. 2019 елның 30 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта Үзәк урамының 1йортында урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында халык җыенын уздырырга.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез, 2020 елда Янсуар авыл җирлеге Нырсуар торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 төркем инвалидларны, 5 һәм аннан да күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләрне бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Янсуар авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Питрәч муниципаль районы
Янсуар авыл җирлеге башлыгы В.Н. Таланов

СОВЕТ ЯНЦЕВАРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ